

Халыкара бәйрәм доньядагы тел-ләрне саклау, аларны киләчәк буынга исән-имин житкерv макстатыннан оешкан.
Һәр  халыкнын теле vзенчәлекле. Кvп телләр белv доньяга карашны кинәйтә,  торле милләт халкынын мәдәниятен тирәнрәк белергә ярдәм итә. Безнен  телебез – татар теле, шуна кvрә һәр татар кешесе vз теленә хормәт белән  карарга тиеш. Телебезнен кулланылыш даирәсен кинәйтv, аны балаларыбызга  һәм оныкларыбызга тапшыру – безнен топ бурычыбыз. Шул бурычны Мордовиядә  тормышка ашырып килергә тырышабыз, булдыра алган кадәр. Мордовиянен  татар телле мәктәпләрендә шул бурычны да тормышка ашырып киләләр. Мона  дәлил итеп, Туган тел коне турында берничә мәгълумат.

Ромодан районы Алтар урта гомуми белем бирv мәктәбендә 19 нчы февральдән  24-нче февральгә кадәр Туган телләр атналыгы узган. 21 февральдә  билгеләп vтелә торган Халыкара туган тел коне алдыннан татар теле һәм  әдәбияты укытучысы Венера Галләм кызы Конешева 5-9 сыйныф укучылары  арасында “Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел” дигән викторина  vткәргән. Татар һәм рус халыкларынын тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәтләре  турында да сvз барган.
Халыкара туган тел конендә Дубенка районы  Кочкурово урта мәктәбенен тәрбия буенча директор кинәшчесе Альфия Кетдюс  кызы Узбякова 2 сыйныф укучылары белән “Туган телне бел һәм ярат!”  дигән чара vткәргән.
Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе  укытучысы Сания Спартак кызы Саляева житәкчелегендә “Туган телемдә  укыйм” Ботенроссия акциясендә укучыларнын сәнгатьле шигырьләр  сойләгәннәре интернет челтәрдә. Латышовка урта мәктәбендә торле  чараларны татар теле һәм әдәбияты укытучысы Светлана Равиль кызы



Поташова  да vткәргән. Ә Большие Поляны топ мәктәбенен 7 сыйныф укучысы Кильдеев  Рамазан (укытучысы Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева) татар телендәге шигыре  белән “Туган телемдә укыйм” Ботенроссия акциясендә катнашкан. Туган  телендә барлык әтиләрне 23 февраль бәйрәме белән дә котлаган.
Ләмберә  районы Ләм-берәнен №1 мәктәбендә, Черемиш топ мәктәбендә торле чаралар, очрашулар vткән. Татар Тавла топ мәктәбе сайтында татар теле һәм  әдәбияты укытучысы Альфия Фатих кызы Муртазина Халыкара туган тел конен  Габдулла Тукайга багышлап эчтәлекле чара vткәрә. Ботенроссия акциясендә  дә катнашкан-нар. Шул ук районнын Пензятка урта мәктәбендә Туган тел  конендә һәрбер сыйныфта кызыклы чаралар vткән. Шулар арасында ана телен,  тарихыбыз һәм мәдәниятебезне саклауда татар халкы аш-суынын бай тарихы,  vзенчәлекләре һәм кызыклы традицияләре дә зур

роль уйный торган ярыш та  бар. Чаралар арасында аш-су конкурсындагы пәрәмәчләр, кош теле һәм,  әлбәттә, чәк-чәк пешерv дә телебезне, мәдәниятыбызны кадерләргә ярдәм  итә.
2024 елнын 21 февралендә “Педагог 13.ру”да Халыкара туган тел  конена багышланган «Туган тел – халык жаны» тобәкара тvгәрәк остәле  узган. Чара эшендә Мордовия Республикасы һәм Россия Федерациясе  тобәкләре (Ульяновск, Оренбург, Белгород олкәләре, Татарстан  Республикасы) мәгариф оешмаларынын туган (рус, мокша, әрзә, татар) теле  педагоглары катнашкан.
Тобәкара тvгәрәк остәлнен модераторы булып  этномәдәни белем бирv лабораториясе модире Елена Михайловна Наумова  билгеләп vткәнчә, Ватаныбыз очен vз халкынын мәдәниятен,  гореф-гадәтләрен саклап калу, фикер йортә, туган телдә сойләшә белv бик  моһим. Мен еллар дәвамында ул безнен ата – бабаларыбызнын кvп буыннары тарафыннан барлыкка китерелгән һәм анын һәр сvзе саф алтын бортеге  кебек.
Туган телегезне яратыгыз һәм саклагыз!

**Наилә НАСЫРОВА**